| СОВЕТ БОЛЬШЕШУРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШУРНЯК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

| РЕШЕНИЕ | Олы Шурняк авылы | КАРАР |
|---|---|---|

№ 137 « 23» октябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советының 14.12.2018 елның 142 № - лы «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советы

Карар кылдым:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советының 14.12.2018 № 142 Карары белән расланган» Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларның дәвамлылыгы мондый проект басылып чыккан көннән алып бер айдан да артмый.».

1.2. 13 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гавами тыңлауларны уздыру срогы муниципаль берәмлек халкына аларны уздыру турында хәбәр иткән көннән алып гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр ундүрт көннән кимрәк һәм утыз көннән артык була алмый.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәис Н.И.Мельников